**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.03.2017 Балык Бистәсе штп. № 38пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 202п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалар булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 202п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 6 февралендәге 17 пи номерлы, 2014 елның 20 февралендәге 28 пи номерлы, 2015 елның 25 февралендәге 61 пи номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299пи номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299пи номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299пи номерлы, 2016 елның 11 маендагы 68 пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 1.3 пунктның беренче һәм икенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү «Татарстан Республикасында халыкның аерым

категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге № 542 карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Компенсация билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар (алга таба - исәп-хисап чоры) белән компенсация билгеләү турында гариза биргән айга кадәр соңгы алты календарь ай эчендә билгеләнә.»;

1.2) 2.1 пунктның «б " пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) гаиләнең һәр әгъзасының өстәмә компенсация бирү турында гариза бирү аеннан алдагы алты ай өчен керемнәре турында документлар;»;

1.3) 2.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге бүлекчәләренә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан, шул исәптән ведомствоара электрон бәйләнешнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган региональ ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системаларын кулланып, эш бирүче (иминләштерүче) физик зат файдасына исәпләнгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматны алырга мөмкинлек бирә торган мәгълүмати бәйләнешне керткәннән соң, компенсацияне билгеләү аның ризалыгы белән, алынган белешмәләр нигезендә, мөрәҗәгать итүчедән компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән 12 айдан соңгы 6 ай эчендә башкарыла.».

2.Әлеге карарны Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда кабул итү: http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Д.Ә.Низамов